МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.05.2016 г. Казань № __под-1059/16

**Татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен 2016 елда исемле стипендияләрне гамәлгә кую турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасын раслау турында» 25.10.2013, № 794 карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасын тормышка ашыру буенча чаралар планының 3.5.3 пунктына тәңгәл рәвештә боерык бирәм:

1. Татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен 2016 елда исемле стипендияләрне гамәлгә куярга.

2. Татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләргә дәгъва кылуга конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәне (1 нче кушымта) расларга.

3. 2016 елның IV кварталында Татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләргә дәгъва кылуга конкурс уздырырга.

4. Татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләргә дәгъва кылуга конкурсның экспертлар советы составын (2 нче кушымта) расларга.

5. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмаларына хезмәткәрләренең конкурста актив катнашуын оештырырга тәкъдим итәргә.

6. Бу Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И. Поминовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр
Э.Н.ФӘТТАХОВ

Татарстан Республикасы Мәгариф
һәм фән министрлыгының 2016 елның
31 маендагы № под-1059/16
боерыгына 1 нче кушымта

**ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫННАН ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ КАДРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА ФӘННИ-ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕК БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮЧЕ ЯШЬ ҺӘМ ӘЙДӘП БАРУЧЫ ГАЛИМНӘР ӨЧЕН ИСЕМЛЕ СТИПЕНДИЯЛӘРГӘ ДӘГЪВА КЫЛУГА КОНКУРС УЗДЫРУ ТӘРТИБЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасын раслау турында» 25.10.2013, № 794 карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасы кысасында тормышка ашырыла.

1.2. 2016 елның IV кварталында татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләргә дәгъва кылуга конкурс (алга таба – Конкурс) турында мәгълүмат http://mon.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына «Чаралар» бүлегенә урнаштырыла.

1.3. Конкурс Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан уздырыла.

1.4. Конкурсның максаты булып, татар телен һәм әдәбиятын укыту өлкәсендәге фәнни һәм фәнни-педагогик кадрларның сыйфат составын яхшырту өчен шартлар тудыру тора.

Конкурсның бурычлары булып торалар:

фәнни-педагогик хезмәткәрләрнең статусын күтәрү һәм социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

яшь галимнәр санын арттыру һәм Россия яшьләрнең фән һәм мәгариф өлкәсендә урнашып калуына булышлык итү;

татар телен һәм әдәбиятын укытуның алдынгы тәҗрибәсен файдаланучы фәнни-педагогик кадрлар санын арттыру;

татар филологиясе өлкәсендә фәнни казанышларны популярлаштыру.

1.5. Исемле стипендияләр бүлеп бирү Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабыннан башкарыла.

Конкурс җиңүчеләренә бирелә:

70000 сум күләмендәге 10 стипендия – татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче әйдәп баручы галимнәр өчен;

30000 сум күләмендәге 10 стипендия – татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь (40 яшькә кадәр) галимнәр өчен.

## 2. КОНКУРСТА КАТНАШУ ШАРТЛАРЫ

2.1. Конкурста катнашуга югары белем бирүче мәгариф оешмаларының татар филологиясе өлкәсендә эшләүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәре чакырыла.

Конкурста катнашу индивидуаль булып тора.

2.2. Конкурста татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендияләргә дәгъва кылуга 2014 һәм 2015 елларда уздырылган конкурсларда җиңүче дип танылган яшь һәм әйдәп баручы галимнәр катнаша алмый.

2.3. Дәгъва кылучыларга таләпләр.

2.3.1. Соңгы 5 елда татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче әйдәп баручы галимнәр өчен стипендияләргә дәгъва кылучылар тиеш:

татар телен һәм әдәбиятын укыту өлкәсендә кимендә 15 ел фәнни-педагогик стажга (хезмәт кенәгәсе күчермәсе белән раслана) ия булырга;

2015-2016 елларда Татарстан Республикасының мәгариф системасы өчен актуаль гамәли тикшеренүләр нәтиҗәләрен чагылдыручы фәнни мәкаләләре булырга;

халыкара нәшриятларда басылып чыккан кимендә 1 монографиясе (монография кисәге) һәм Россия нәшриятларында – кимендә 2 монографиясе (монография кисәкләре) булырга (титул битенең күчермәсе кушып бирелә, басылып чыккан урынның электрон адресы күрсәтелә);

Югары аттестация комиссиясе киңәш иткән басмаларда кимендә 5 фәнни мәкаләсе булырга (күчермәсе кушып бирелә, басылып чыккан урынның электрон адресы күрсәтелә);

татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә 2015-2016 елларда тормышка ашырылган фәнни проекты булырга;

татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә татар телен һәм әдәбиятын дөнья күләмендә популярлаштыру буенча мәгърифәт эшчәнлеге алып баручы халыкара фән һәм мәгариф проектларында катнашырга;

татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендә дәүләтнең программа-норматив документларын әзерләүдә катнашырга (документлар исемлеге кушып бирелә);

халыкара, бөтенроссия һәм республикакүләм фән-мәгариф чараларын, конкурслар, олимпиадаларны әзерләүдә һәм уздыруда катнашырга (чаралар исемлеге кушып бирелә);

грант проектларының (Россия гуманитар фәнни фонды, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды, Россия фәнни фонды) җитәкчесе һәм (яки) башкаручысы сыйфатында катнашырга (проектларның №, урнаштырылган мәгълүмат сайты күрсәтелә);

ел саен фәнни тикшеренү юнәлешендәге кимендә 3 халыкара конференция эшендә катнашырга (доклад сөйләргә).

2.3.2. Соңгы 5 елда татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь галимнәр өчен стипендияләргә дәгъва кылучылар тиеш:

кимендә 5 ел фәнни-педагогик стажга (хезмәт кенәгәсе күчермәсе белән раслана) ия булырга;

2015-2016 елларда Татарстан Республикасының мәгариф системасы өчен актуаль гамәли тикшеренүләр нәтиҗәләрен чагылдыручы фәнни мәкаләләре булырга;

Югары аттестация комиссиясе киңәш иткән басмаларда кимендә 3 фәнни мәкаләсе булырга (күчермәсе кушып бирелә, басылып чыккан урынның электрон адресы күрсәтелә);

татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә 2015-2016 елларда тормышка ашырылган фәнни проекты булырга;

татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендә дәүләтнең программа-норматив документларын әзерләүдә катнашырга (документлар исемлеге кушып бирелә);

татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә республикакүләм фәнни һәм мәгариф

проектларында катнашырга (чаралар исемлеге кушып бирелә);

грант проектларының (Россия гуманитар фәнни фонды, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды, Россия фәнни фонды) җитәкчесе һәм (яки) башкаручысы сыйфатында катнашырга (проектларның №, урнаштырылган мәгълүмат сайты күрсәтелә).

2.3.3. Конкурсга катнашу өчен, катнашучылар, бу Нигезләмәнең 2.3.1, 2.3.2 пунктлары билгеләгән документларны кушып, Конкурста катнашучы анкетасын (1 нче кушымта) тапшыра.

(2.3 пункт – ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 21.09.2016, № под-2015/16 боерыгы редакциясендә)

2.4. Конкурс кысасында каралмый яки караудан төшереп калдырыла:

бу Нигезләмәнең 2.3.1, 2.3.2 пунктларында күрсәтелгән таләпләргә туры килмәүче анкета-гаризалар;

Конкурста катнашуга гариза бирү срогыннан соңрак кергән эшләр.

## 3. КОНКУРСНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ

3. Конкурс ике этапта уздырыла:

3.1. I этап. Әзерлек.

Конкурсның башлануы, шартлары һәм тәртибе турында барлык мәнфәгатьле җаваплы затларга хәбәр итү Министрлыкның сайтында 2016 елның 10 октябренә кадәр башкарыла.

Югары белем бирүче мәгариф оешмаларында Конкурста катнашучыларның кандидатураларын билгеләү буенча әзерлек эше үткәрелә.

Конкурс документларын җыю һәм теркәү Министрлыкта 2016 елның 10 ноябренә кадәр башкарыла.

3.2. II этап. Конкурска тапшырылган материалларга экспертиза уздыру  һәм 2016 елның 30 ноябренә кадәр Конкурсның җиңүчеләрен ачыклау.

Экспертлар советының составы Министрлык боерыгы белән раслана.

Конкурска тапшырылган материалларга экспертиза экспертлар советы утырышында бу Нигезләмәнең 2.3 пунктында бәян ителгән таләпләргә туры китереп тапшырылган документларны тикшерү юлы белән уздырыла. Экспертлар советының барлык әгъзалары катнашу шарты үтәлгәндә, утырыш юридик көчкә ия дип санала.

Экспертиза нәтиҗәләре нигезендә, әйдәп баручы галимнәр һәм яшь галимнәр арасында дәгъва кылучылар рейтингы формалаштырыла.

Рейтингны төзү өчен критерийлар булып, бу Нигезләмәнең 2.3 пунктына тәңгәл рәвештә тапшырылучы мәгълүматлар хезмәт итә. Рейтингтагы урынны өскәрәк күтәрү өчен (тигез дәрәҗәдә) нигезләр:

минималь фәнни-педагогик стажга өстәмә һәр ел;

һәр өстәмә монография;

2015-2016 елларда Татарстан Республикасының мәгариф системасы өчен актуаль гамәли тикшеренүләр нәтиҗәләрен чагылдыручы һәр өстәмә мәкалә;

Югары аттестация комиссиясе киңәш иткән басмалардагы һәр өстәмә мәкалә;

халыкара фән һәм мәгариф проектларында һәр өстәмә катнашу;

дәүләтнең программа-норматив документларын әзерләүдә һәр өстәмә катнашу;

халыкара, бөтенроссия һәм республикакүләм фән-мәгариф чараларын, конкурслар, олимпиадаларны әзерләүдә һәм уздыруда һәр өстәмә катнашу;

грант проектларының җитәкчесе һәм (яки) башкаручысы сыйфатында һәр өстәмә катнашу;

халыкара конференцияләр эшендә һәр өстәмә катнашу (доклад сөйләү).

Әйдәп баручы галимнәр һәм яшь галимнәр рейтингының беренче 10 юлына эләккән дәгъва кылучылар Конкурсның җиңүчеләре дип танылa.

Эш нәтиҗәләре экспертлар советының барлык әгъзалары тарафыннан имзаланучы беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм, Конкурсның икенче этабы тәмамланугa кадәр 2 эш

көненнән соңга калмыйча, Министрлыкка җибәрелә.

Экспертлар советы карары Министрлык боерыгы белән раслана. Конкурс йомгаклары бары тик суд тәртибендә генә яңадан каралырга мөмкин.

(3.2 пункт – ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 21.09.2016, № под-2015/16 боерыгы редакциясендә)

3.3. Конкурс җиңүчеләре стипендияләр һәм дипломнар белән 2016 елның 25 декабренә кадәр бүләкләнә.

Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат http://mon.tatarstan.ru адресы буенча Министрлыкның сайтына 2016 елның 25 декабренә кадәр урнаштырыла.

## 4. ФИНАНСЛАУ

4.1. Конкурсны оештыруга бәйле чаралар Татарстан Республикасы бюджетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасын тормышка ашыру өчен алдан билгеләнгән акчасы хисабыннан уздырыла.

1 нче кушымта

Татар теле һәм әдәбиятыннан югары квалификацияле кадрлар әзерләү буенча фәнни-педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүче яшь һәм әйдәп баручы галимнәр өчен исемле стипендиягә дәгъва кылучы
АНКЕТАсы

Теркәү көне: ________________ Гариза номеры: _______________

1. Гариза бирүченең Ф.И.О.
2. Элемтәгә керү өчен мәгълүмат (телефон (нар), e-mail).
3. Туган көне.
4. Гыйльми дәрәҗәсе һәм исеме.
5. Төп эш урыны (оешманың атамасы, ведомство, шәһәр, биләгән вазифасы).
6. Фәнни-педагогик стажы (хезмәт кенәгәсе күчермәсе белән раслана).
7. Дәгъва кылучының резюмесы (1 биттән артык түгел).
8. Басмалары чыккан урынның электрон адресын күрсәтеп, басмаларының исемлеге (Нигезләмәнең 2.3 пунктына туры килүче һәм эшләренең күчермәләре белән дәлилләнгән).
9. Татар теле һәм әдәбияты өлкәсендә дәгъва кылучы катнашкан халыкара фәнни һәм мәгариф проектлары (тапшыру формасы ирекле).
10. Татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү һәм укыту өлкәсендә дәгъва кылучы аларны булдыруда катнашкан дәүләт программа-норматив документлары исемлеге (тапшыру формасы ирекле).
11. Дәгъва кылучы аларны оештыруда һәм уздыруда катнашкан халыкара, бөтенроссия һәм республикакүләм фәнни-мәгариф чаралары, конкурслар, олимпиадалар исемлеге (тапшыру формасы ирекле).
12. Дәгъва кылучы аларда җитәкче һәм (яки) башкаручы сыйфатында катнашкан (яки катнаша торган) грант проектлары (Россия гуманитар фәнни фонды, Россия фундаменталь тикшеренүләр фонды, Россия фәнни фонды) исемлеге.
13. Халыкара конференцияләрдә фәнни тикшеренүләре юнәлешендә үзе катнашып сөйләгән докладлары исемлеге.
14. Өстәмә мәгълүмат.
14.1. Татар филологиясе буенча диссертация советларындагы әгъзалыгы (советларның номерларын күрсәтергә).
14.2. Татар филологиясе өлкәсендә халыкара дәрәҗәдәге фәнни матбугат басмаларын әзерләүдә һәм нәшер итүдә катнашуы (документның, басманың күчермәсе белән дәлилләнә).
14.3. Диссертациясенә кирәкле тикшеренү темасы һәм соңгы 5 елда басылып чыккан мәкаләләре исемлеге.
15. Дәгъва кылучының имзасы.
16. Дәлилләүче документларның күчермәләре.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 31 маендагы № под-1059/16 боерыгына 2 нче кушымта

**ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫННАН ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ КАДРЛАР ӘЗЕРЛӘҮ БУЕНЧА ФӘННИ-ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕК БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНҮЧЕ ЯШЬ ҺӘМ ӘЙДӘП БАРУЧЫ ГАЛИМНӘР ӨЧЕН 2016 ЕЛДА ИСЕМЛЕ СТИПЕНДИЯЛӘРГӘ ДӘГЪВА КЫЛУГА КОНКУРСНЫҢ ЭКСПЕРТЛАР СОВЕТЫ СОСТАВЫ**

1. Мөхәммәтов Илдар Ринат улы, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары, рәис.
2. Йосыпова Әлфия Шәүкәт кызы, филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегендәге гомуми һәм төрки телләрне өйрәнү кафедрасы профессоры, рәис урынбасары.
3. Галиуллина Гөлшат Рәис кызы, филология фәннәре докторы, Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегендәге татар телен өйрәнү кафедрасы доценты.
4. Галиуллин Радик Рамил улы, филология фәннәре кандидаты, Чаллы дәүләт педагогика университетының татар теле һәм әдәбияты, аларны укыту методикасы кафедрасы доценты.
5. Гусев Святослав Николаевич, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының фәнни-техник сәясәт бүлеге начальнигы.
6. Динмөхәммәтова Эльвира Николаевна, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегендәге гомуми һәм төрки телләрне өйрәнү кафедрасы доценты.
7. Заһидуллина Дания Фатыйх кызы, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең баш гыйльми сәркатибе.
8. Мохтәсимова Гөлназ Ринат кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегендәге гомуми һәм төрки телләрне өйрәнү кафедрасы доценты.
9. Нурмөхәммәтова Раушания Сәгъдәтҗан кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегендәге гомуми һәм төрки телләрне өйрәнү кафедрасы доценты.
10. Саттарова Мәдинә Рәшит кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегендәге гомуми һәм төрки телләрне өйрәнү кафедрасы доценты.
11. Хисамов Олег Ришат улы, филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институы директорының фәнни эш буенча урынбасары.
12. Шәрипова Алсу Сәмигулла кызы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге начальнигы.
13. Йосыпова Нурфия Марс кызы, филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлегендәге татар әдәбияты кафедрасы доценты.